Р.Нурмөхәммәтова,
ТДГПУ доценты

# Татар халкының матди мәдәниятен чагылдырган лексик берәмлекләр буларак кием-салым атамалары

Милли тел - милләтнең мөһим билгеләреннән берсе. Тел - шушы телдә сөйләшүче халыкның милли мәдәнияте хәзинәсе. Хәзерге вакытта тел белемендә тел һәм мәдәният нисбәтен милли үзенчәлекләргә бәйләп карауга көннән-көн зуррак игътибар бирелә. Тел милли мәдәният формалашуда иң мөһим урыннарның берсен алып тора. Халыкның бөтен тормыш тәҗрибәсе һәм барлык мәдәни казанышлары телдә теркәлә, анда көзгедәге кебек чагыла. Мәдәният гаҗәеп күп санлы матди һәм рухи элементлар җыелмасыннан гыйбарәт. Алар тел системасының барыннан да бигрәк лексикасында гәүдәләнеш таба. Аерым бер этносның дөньяны танып-белү үзенчәлекләре, милләтнең матди һәм рухи мәдәниятенә караган сыйфатлар телнең лексик дәрәҗәсендәге берәмлекләргә туплана. Тел мәдәниятне бер мизгелгә генә чагылдырып калмый, аның элеккеге хәлен теркәп куя һәм кыйммәтен буыннан-буынга тапшыра. Телнең сүзлек составын төрле яклап өйрәнү тел белемендә элек-электән мөһим мәсьәләләрдән саналды, шунлыктан аның белән кызыксынуларның кимегәне юк.

“Мәдәният” - күпмәгънәле төшенчә. Фәнни яктан караганда, кешенең бөтен иҗтимагый эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм процесслары җыелмасын *мәдәният* дип атыйлар һәм аны кешегә бәйле булмаган тышкы шартларга, ягъни табигатькә каршы куялар. Димәк, кешене чолгап алган чынбарлык табигатьтән һәм мәдәнияттән гыйбарәт.

Халык мәдәнияте аның үткәненә һәм хәзергесенә караган барлык күренешләрне үз эченә ала. Мәдәниятне *матди* һәм *рухи мәдәният* дигән төрләргә бүләләр. Матди мәдәнияткә җәмгыятьнең җитештерүче көчләрен һәм шулар белән бәйле барлык әйберләрне, ә рухи мәдәнияткә сәнгать, дин, фән, фәлсәфәне кертәләр. Бу бүленешне җентекләбрәк карасак, матди мәдәният

кешенең шәхси “тән” ихтыяҗларын канәгатьләндерсә, рухи мәдәният гомумкешелек сәләтләрен – күңел халәтен формалаштыра, дияргә мөмкин.

Матди мәдәниятне чагылдырган предметлар, нигездә, көндәлек тормыш-көнкүреш өлкәсендә кулланыла. Көнкүреш лексикасы һәм матди мәдәният күренешләрен чагылдырган сүзләр күпмедер дәрәҗәдә туры килә, алар матди мәдәниятнең төп өлешләре буларак карала. Теләсә кайсы телнең сүзлек составында әлеге халыкның тормыш-көнкүрешенә караган лексика шактый зур урын били. Нәкь менә аларда яшәү өчен иң мөһим предметлар һәм күренешләр ачык чагылыш таба. Көндәлек кирәк-яраклар, ашамлыклар, кием, торак матди мәдәниятне өйрәнүдә төп чыганак объектларны тәшкил итәләр.

Көнкүреш сүзләре тормышның төрле якларын үз эченә ала һәм иң зур предметлы-тематик төркемнәрнең берсен тәшкил итә, аны үз эчендә күп кенә лексик-семантик төркемчәләргә аерып карап була. Лексиканы лексик-семантик төркемчәләргә бүлеп тикшерү телләрнең сүзлек байлыгын өйрәнгәндә иң ышанычлы методларның берсе санала. Сүзләрнең мондый төркемчәләрен аерып чыгару предметларның үзләрен классификацияләүгә нигезләнә, чөнки лексика тышкы факторлар белән бик тыгыз бәйләнештә тора.

Телнең сүзлек байлыгын тулаем алып тикшерү гаять кыен һәм мөмкин дә түгел. Чөнки лексика телнең иң хәрәкәтчән өлкәләреннән санала, нәкь менә ул “чорлар бәйләнешен” тәэмин итә: анда җәмгыятьнең элеккеге һәм хәзерге матди һәм рухи мәдәнияте турында мәгълүмат табарга була. Телнең аерым бер үсеш чорындагы сүзләрен күпмедер дәрәҗәдә тотрыклы хәлендә өйрәнү өчен сүзлекләр ышанычлы кулланма булып хезмәт итәләр.

Мәгълүм булганча, сүзлекләр төрле була. Аңлатмалы сүзлекләрдә телдәге сүзләрнең зур күпчелеге теркәлә, ә тәрҗемәле сүзлекләр, гадәттә, телнең лексикасындагы иң актив сүзләрне туплап бирә, чөнки ике телдә аралашуның төп шарты – телнең төп сүзлек запасыннан хәбәрдар булу. Әлеге фикерләрдән чыгып, татар халкының матди мәдәниятен чагылдырган лексиканың бер өлешен – кием-салым атамаларын өйрәнү өчен, без XX гасыр ахырында чыккан “Татарча-русча сүзлек”кә мөрәҗәгать иттек һәм мисалларны шул хезмәттән

тупладык. Кайсы гына сүзлекне алып карасаң да, сүзлекләрдә лексик материал шактый булуга карамастан, алар телнең сүзлек байлыгын тулаем чагылдыра алмаганын барлык кешеләр дә яхшы аңлый, шунлыктан без дә тикшерелә торган лексик төркемнең аерым бер фрагменты турында гына фикер йөртәчәкбез.

Татар телендә "**КИЕМ**" мәгънәсендәге лексик катлам гаять зур, бу хәл әлеге көнкүреш предметларының кеше тормышында мөһим урын алып торулары белән аңлатыла. Европаның шактый кырыс шартларында киемнән башка тереклек итү мөмкин түгел: ул салкыннан һәм эсседән, яңгырдан һәм кардан, җилдән саклый; шул ук вакытта эстетик функция дә үти, ягъни кеше кием белән үзен тыштан берникадәр бизи дә. Шунлыктан без бу төркемгә, "чын" кием-салым атамаларыннан тыш, бизәнү предметларын да кертеп карауны максатка ярашлы дип таптык. Сүзлек составының XX гасыр ахырына кадәр сакланып килеп җиткән әлеге төркемендә татар халкының милли һәм элеккеге кием атамаларыннан тыш (аларның да күбесе тарихи лексикага карый), халыкара кулланылышта йөргәннәренең дә күпсанлы булуын күрү кыен түгел. Халыкның көнкүреш хәле яхшыру, җиңел сәнәгатьнең алга китүе, моданың үзгәреп торуы һәм халыкара статус алуы татарлар куллана торган бу төр предметларга тәэсир итми калмаган һәм тел дә үз чиратында бу үзгәрешләрне лексик берәмлекләрдә чагылдырырга тырышкан.

Матди мәдәниятка караган лексиканың "Кием-салым һәм бизәнү әйберләре атамалары" тематик төркемен үз эчендә берничә төркемчәгә бүлеп карау отышлы, аларда бу предметларның үтәгән функцияләре ачык чагылыш таба.

**1. Кием-салым предметларын гомумиләштереп атый торган сүзләр:** *кием, күлмәк-ыштан. Кием* сүзе тукымадан, мехтан, күннән һ.б. материаллардан тегелгән, эшләнгән һәм тәнне каплау өчен хезмәт итә торган әйбер, һәртөрле киемнәрне атый. *Күлмәк-ыштан* сүзе дә бер кат өске киемне җыйнап атау өчен кулланыла.

**2. Өске кием һәм аның аерым өлешләрен белдерә торган атамалар:** *алъяпкыч, балак, билбау, бишмәт, бурка, бушлат, гамаш, гимнастерка,*

*жакет/жикет, жилет, итәк, камзул, каплама, капот, кафтан, кесә, кимоно, кожан, комбинезон, костюм, кофта, куртка, кыса, камәр, күлмәк, пальто, пиджак, плащ, пута, пәрәнҗә, сарафан, свитер, телогрейка, толып, тун, фрак, френч, фуфайка, халат, чадра, чалбар, чапан, чикмән, ыштан, эзәр, юбка, яка, әрмәк, җилән һ.б.* Бу төркемдәге кайбер предметлар бүгенге көндә инде кулланылыштан чыкканнар. Мәсәлән, *бишмәт, бушлат, кафтан, фуфайка, әрмәк, җилән* кебек киемнәрне хәзер музейларда гына күрергә мөмкин. *Капот* (хатын-кызларның киң итеп тегелгән өйдә кия торган күлмәге) дип аталган күлмәкне дә хатын-кызларыбыз инде кими торгандыр. Кавказлылар бөркәнә торган җиңсез, плащсыман киң йонлач кием – *бурка* татар халкында элек тә бик үк популяр булмагандыр диясе килә. *Билбау, камәр, пута, эзәр* сүзләре киемнең бер үк элементын белдергәнгә, кайберләре пассивлашкан.

**4. Эчке кием:** *бюстгалтер, кальсон, корсет, күкрәкчә, лифчик, пижама, трико* һ.б. Бу төркемдә бары тик *күкрәкчә* дип аталган эчке кием генә кулланылыштан чыккан.

**5. Баш киемнәре:** *башлык, берет, бөркәнчек, бүрек, калпак, калфак, картуз, кепка, косынка, кубанка, кәләпүш, кәпәч, көрәпәлә, тастар, фуражка, чалма, шарф, фәс, шәл, шәльяулык, эшләпә, яулык* һ.б. Бу баш киемнәре арасында *картуз* – ирләрнең козыреклы баш киеме, *кашбау* – алгы ягы сәйлән, энҗе, асылташлар белән бизәлгән тасма яки такыясыман хатын-кыз баш киеме, *тастар* – кияүгә китәсе кызлар башларына сарып йөри торган озынча ак киндер яулык гомумән тарихта калган. *Кәпәч* – түбәтәй, *көрәпәлә* - кайбер өске киемнәрнең очлы башлыгы, капюшон бүгенге көндә дә киелә торган баш киемнәренең искергән атамалары булып калган. *Чалма* һәм *фәс* дини атрибут буларак хәзер дә кулланылышта.

**6. Аякка киелә торган кием һәм аның өлешләрен атый торган сүзләр:** *аякчу, балтыр, башмак, бота, ботинка, будыргыч, бурка, бәйләвеч, галош, итек, калош, ката, киндерә, куныч, кәвеш, күтәртмә, оек, оекбаш, олтан, олтырак, оектоткыч, пима, сандал, туфли, чабата, читек, чүәк, ыштыр* һ.б. Бу төркемдәге кайбер сүзләрнең белдергән предметлары кулланылыштан

төшеп калган: *аякчу* – аяк чолгавы, *будыргыч* – тарттырып будырып куя торган сузылмалы (резинкалы) тасма, *бурка* – кунычы юка киез яки сырылган тукымадан булган күн табанлы аяк киеме, *күтәртмә* - язын яки көзен чабатага су үтмәсен өчен аның астына беркетелгән ике агач шакмак, *оектоткыч* – оек будыргыч, *чабата* – юкә, карама каерылары яки каешның телемле тасмаларыннан үреп ясалган баулы сай аяк киеме, *ыштыр* – киндер, фланель яки башка тукыма кисәгеннән ясалган аяк чолгавы.

**7. Кулга киелә торган кием атамалары:** *бишбармак, бияләй, перчатка* һ.б. Кулны салкыннан саклау өчен кешелек әлегә кадәр болардан да уңайлырак әйберләр уйлап таба алмаган, б*ишбармак* сүзе хәзерге көндә пассиврак кулланыла, аерым җирле сөйләшләрдә генә очрый.

**8. Бизәнү әйберләре атамалары:** *алка, балдак, бант, беләзек, брошка, булавка, галстук, изү, ишмә, йөзек, кадавыч, каеш, кулбау, кулон, муенса, мәрҗән, парик, тарак, тасма, хәситә, чулпы, чылбыр, чәчкап, чәчүргеч, җилпәзә* һ.б. *Изү* – татар хатын-кызларының төрле төстәге тасмаларны изү тирәли тегеп, укалар белән чигеп, тәңкәләр һ.б. зиннәтләр белән бизәп эшләнгән, күлмәк якасыннан алып билгә кадәр бөтен күкрәкне каплый һәм бизәнү өчен күлмәк өстеннән киелә торган күкрәкчәсе*, ишмә* - тимер яки бакыр чыбыкка көмеш җепләр урап ясалган беләзек*, хәситә* - күлмәк өстеннән киелә торган, алтын-көмеш акчалар һәм ука асылташлар белән бизәлгән күкрәкчә, *чулпы* – чәч толымына кушып үрелә торган тасма очына тагылган бизәнү әйберсе*, чәчкап* – электә татар хатын-кызларының чәч толымнарын каплап йөртә торган, тәңкәләр белән бизәлгән, тукымалардан ясалган баш киеменә өстәмә әйбер. Бу бизәнгечләрне хәзер хатын-кызларыбыз инде кулланмый, аларны фольклор ансамбльләренең чыгышларында гына күрү бәхетенә ирешәбез. *Беләзек, кулбау* сүзләрен *браслет* сүзе алыштырды, *кадавыч* сүзенең дә русча вариантларын (заколка, приколка, шпилька) яратыбрак кулланабыз.

**9. Кием-салым җитештерүдә кулланыла торган корал атамалары:** *бишинә, инә, кайчы, киерге, киергеч, кәтүк, энә* һ.б. Бу тегү-чигү кораллары хәзер дә ят түгел, шуңа күрә сүзләре дә күпчелек кешегә таныш.

**10. Кием-салым җитештерүдә кулланыла торган тукымалар һәм материаллар:** *акбүз, алача, астар, асыл, атлас, батист, бостон, бумази, бәз, бәрхәт, бүз, вельвет, габардин, ефәк, замш, кашемир, киез, киндер, кисея, киҗе, коленкор, комач, креп, крепдишин, кримплен, кытат, кәҗүл, күн, лавсан, материя, материал, нейлон, панбәрхет, парча, плюш, постау, саржа, сатин, ситсы, сукно, тегәрҗеп, торыпша, трикотаж, тукыма, тула, фетр, фланель, хәтфә, чүпрәк, эчлек, әдрәс, җеп, җитен* һ.б. Тукымалар мода үзгәрүгә бәйле рәвештә кулланылыштан чыгалар. Мәсәлән, хәзер *акбүз, батист, бостон, бүз, габардин, коленкор, комач, креп, крепдешин, кримплен, кытат, лавсан, нейлон, плюш, постау, саржа, сукно, торыпша, тула* кебек тукымалардан тегелгән киемнәрне кибет киштәләрендә очрату мөмкин түгел.

**11. Кием-салымны бизәүгә бәйле терминнар:** *ажур, аса, бизәк, бөрмә, зияк, инеч, кайма, канва, кант, каптырма, каптыргыч, күчергеч, лента, маң, орнамент, сәдәп, сәйлән, тамбур, төймә, чачак, чигеш, чуптар, чәкән, чәмчә, чүпләм, әдеп, җияк* һ.б. Бу төркемгә кергән сүзләр арасында тегүче, чигүче һөнәре вәкилләренә генә хас булганнары шактый, ә *каптырма, каптыргыч, сәдәп, төймә* кебек сүзләр хәзер дә гомумкулланылышка ия.

Аралашу чарасы буларак тел җәмгыять тормышы белән бик тыгыз бәйләнгән. Җәмгыятьтәге үзгәрешләр телдә чагылыш таба. Бу нисбәттән, телнең сүзлек составы үзгәрешләргә гаять сизгер. Теге яки бу күренешләрнең, предметларның кулланылыштан төшеп калуы яки, киресенчә, пәйда булуы телдә дә үзгәрешләр китереп чыгара. Матди мәдәният чагылышы булган кием-салым атамаларында да моны күреп була. Милли киемнәрнең кулланылыштан әкренләп чыга баруы белән бәйле рәвештә барлык кешеләрнең бертөрле киемнәр кия башлавы телнең сүзлек запасындагы бу төркем сүзләрдә дә билгеле бер күләмдә үзгәрешләр белән сыйфатлана.

Соңгы елларда җәмгыятьтә күзәтелгән үзгәрешләр моңарчы күрелмәгән күләмдәге матди мәдәният предметларының һәм аларны атаган сүзләрнең гомумкулланылыштан әкренләп чыга баруына китерде. Шул ук вакытта яңа сүзләр һәм әйберләр тормышыбызга ташкын булып килеп керде һәм кулланыла

башлады. Җәмгыятьнең әлеге “ачыклыгы” милләтләр арасындагы, шул исәптән милли мәдәниятләрдәге чикләрне “юа”, телләрнең лексикасында да, халыкларның тормыш-көнкүрешендә дә охшашлыклар барлыкка килүгә сәбәп була. Әмма телнең лексикасында бер төркем сүзләр гасырлар буена кулланылышта калалар, чөнки алар тормыш итү өчен иң мөһим, беркайчан да әһәмиятен югалтмый торган төшенчә-күренешләрне атыйлар.

Файдаланылган әдәбият

Ахметьянов Р.Г. Общая лексика материальной культуры народов Среднего Поволжья. - М.: Наука, 1989. – 178 с.

Замалетдинов Р.Р. Внутренний и внешний мир носителей татарской культуры через призму языка / Р.Р.Замалетдинов. – Казань: Изд-во Казанск. гос. ун-та, 2003. – 208 с.

Замалетдинов Р.Р. Татарская культура в языковом отражении / Р.Р.Замалетдинов. – М.: Владос; Казань: Мәгариф, 2004. – 239 с.

Замалетдинов Р.Р. Теоретические и прикладные аспекты татарской лингвокультурологии / Р.Р.Замалетдинов. – Казань: Мәгариф, 2009. – 351 с.

Рамазанова Д.Б. Названия одежды и украшений в татарском языке в ареальном аспекте / Д.Б.Рамазанова. – Казань: Масер-Лайн, 2002. – 354 с.

Хайрутдинова Т.Х. Бытовая лексика татарского языка / Т.Х.Хайрутдинова. – Казань: Фикер, 2000. – 124 с.

Юсупова А.Ш. Двуязычная лексикография татарского языка XIX века / А.Ш. Юсупова. – Казань: Изд-во Казанск. гос. ун-та, 2008. – 410 с.

Чыганак

Татарча-русча сүзлек. 3 нче басма. Проф. Ф.А.Ганиев редакциясендә. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1998. – 462 б.